Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлеге составына керүче
Кураково авылында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР

28.11. 2023 ел № 1

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Енабердино авыл җирлегенең
Кураково авылында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Кураково авылында тавыш бирү нәтиҗәләре турында " хисап комиссиясенең .2023 елның 27 ноябрендәге беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Кураково авылында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районының Енабердино авыл җирлегенең Кураково авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга

2. 2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Енабердино авыл җирлегенең Кураково авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, югары һәм урта уку йортларында көндезге бүлектә укучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаиләләреннән тыш, ә 1 төркем инвалидлардан 500 сум күләмендә билгеләргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы? дигән сорауга карарны кабул итәргә

1. Көнчыгыш урамындагы юлны ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
2. юлларны кардан чистарту;
3. 1 берәмлек чүп контейнеры сатып алу.

Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru « Енабердино авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Енабердино авыл җирлеге башлыгы вазифаларын башкаручы Е.Ю.Скворцова